**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Яңа Спас авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 9** **22 декабрь 2025 ел.**

**“Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында” 2018 елның 20 апрелендәге 108 номерлы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

2018 елның 20 апрелендәге 108 номерлы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Советының “Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында” карарына (05.06.2018 ел № 111, 21.11.2018 ел №128, 29.11.2018 ел № 133, 23.09.2020 ел № 7, 30.12.2021 ел №44, 30.09.2022 ел №68, 21.11.2022 ел №72, 27.02.2023 ел №87, 17.06.2024 ел №124, 10.12.2024 ел №141, 06.05.2025ел. № 156 ),

1. Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Советының үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә:

2.2 пунктта «15 389 сум» сүзен «16 928 сум” сүзе белән алыштырырга;

2.14 пунктта « 15 389 сум» сүзен «16 928 сум” сүзе белән алыштырырга.

1.2. Әлеге карар белән расланган “Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренэ, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында” нигезләмәгә 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Яңа Спас авыл җирлеге башлыгына акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның иseme | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 23 201 |

2. Карарны Яңа Спас авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Яңа Спас авыл җирлеге башлыгы, Н.В.Танчук**
**Совет Рәисе**